КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 сентябрь г.Казань № 968

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 ноябрь, 1086 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

исемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктта татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

1.2 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирүче – социаль эшкуарлык өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, социаль предприятие булып торган яки 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат (грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат индивидуаль эшкуар буларак теркәлгән яки юридик затны гамәлгә куючылар (анда катнашучылар) яисә аның акционерлары составына грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп), җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында яисә хуҗалык ширкәтенең җыелма капиталында кимендә 50 процент өлеше яисә акционерлык җәмгыятенең кимендә 50 процент тавыш бирү акцияләре булган физик зат керә) тарафыннан төзелгән, әлеге Тәртипнең тиешле шартларына туры килә торган, бу грантны элек алмаган грант алучыларны сайлап алуда катнашу өчен вәкаләтле органга заявка биргән кече яисә урта эшкуарлык субъекты;»;

алтынчы абзацта «социаль эшкуарлык өлкәсендә проектларны» сүзләреннән соң «яисә эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә проектны» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктның өченче абзацында «социаль эшкуарлар реестрына кертелгән» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктта:

өченче абзацта «проектны тормышка ашыру өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «проектны тормышка ашыру өчен кулланыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «проектны тормышка ашыру өчен кулланыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «проектны тормышка ашыру өчен кирәкле» сүзләрен төшереп калдырырга;

уникенче абзацта «проектны тормышка ашырганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

унбишенче абзацта татар текстында «җитештерү» сүзеннән соң «һәм хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына өстәмә рәвештә грант медицина техникасы, протез-ортопедия эшләнмәләре, программа тәэминаты җитештергәндә һәм (яки) реализацияләгәндә комплектлау әйберләре, шулай ук инвалидлыкны профилактикалау яки инвалидларны реабили-

тацияләү (абилитацияләү) өчен генә файдаланыла алган техник чаралар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.»;

2.1 пунктта:

беренче абзацта «1енә » сүзләрен «15енә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «түләнергә тиешле» сүзләреннән соң «1 мең сумнан арткан» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Заявка бирүче сайлап алуны үткәрү планлаштырыла торган айның 15енә түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара;

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен – ике вариантның берсенә:

1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә социаль предприятие дип танылган һәм аның турында мәгълүмат агымдагы календарь елның 10 июленнән 10 декабренә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән;

2) социаль предприятие дип беренче тапкыр танылган, социаль эшмәкәрлек өлкәсендә эшчәнлек алып бару юнәлеше буенча заявка бирелгән көнгә кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган яки социаль предприятие статусын раслаган, заявка биргән көнгә элек эшләнгән проектны гамәлгә ашыра;

25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат индивидуаль эшкуар буларак теркәлгән яисә юридик затны гамәлгә куючылар (анда катнашучылар) яки аның акционерлары составына грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп), җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында яисә хуҗалык ширкәтенең җыелма капиталында кимендә 50 процент өлеше яисә акционерлык җәмгыятенең кимендә 50 процент тавыш бирү акцияләре булган физик зат керә;

кече һәм урта эшкуарлык субъекты эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру юнәлеше буенча грант алган вакытка кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булган.»;

3.1 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхесне таныклый торган документ күчермәсе (юридик затны гамәлгә куючылар (анда катнашучылар) яки аның акционерлары составына керә торган, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында яисә хуҗалык ширкәтенең җыелма капиталында кимендә 50 процент өлеше яисә акционерлык җәмгыятенең кимендә 50 процент тавыш бирү акцияләре булган 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) юридик затлар һәм индивидуаль эшкуар өчен);»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирүченең социаль эшкуарлык өлкәсендә эшчәнлекне (социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен) яки эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә проектны (25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен) гамәлгә ашыру юнәлеше буенча белем бирү яки акселерация программасын узуы турында заявка тапшырылган көнгә кадәр бер ел эчендә тиешле лицензиясе булган мәгариф оешмасы тарафыннан бирелгән документ (социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен: индивидуаль эшкуарлар, юридик зат җитәкчеләре яки заявка бирүченең тәкъдиме буенча проект җитәкчеләре өчен);»;

3.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 15енче көне хәленә карата Россия Федераль Салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәләре үтәлүе турында салым органы тарафыннан бирелгән белешмә кәгазе яки сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 15енче көне хәленә карата Россия Федераль Салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2016 елның 28 декабрендәге ММВ-7-17/722@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча оешмаларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазе.»

дүртенче абзацта «1енә» сүзләрен «10ысына» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, сайлап алу үткәрелә башлаган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 5.9 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләр һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен заявка бирүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

бу Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

заявка бирүче тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 3.1 – 3.4 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 4.4 – 4.7 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.»;

4.7 пунктның таблицасында:

2 пунктның 2 графасында «социаль предприятиенең» сүзләрен «заявка бирүченең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «4. | Проектны финанслашу күләме | Баллар саны тапшырылган проектны бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 1 дән 5 кә кадәр билгеләнә. |
| 4.1. | 50% һәм аннан да күбрәк | 5 балл |
| 4.2. | Иң күбе 50% | 4 балл |
| 4.3. | Иң күбе 40% | 3 балл |
| 4.4. | Иң күбе 30% | 2 балл |
| 4.5. | 25% | 1 балл»; |

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | Проектны тормышка ашыру территориясе (проект берничә урында тормышка ашырылган очракта, бу бәяләү критерие буенча баллар бергә кушыла) | Баллар саны тапшырылган проектны бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 1 дән 4 кә кадәр билгеләнә. |
| 5.1. | Татарстан Республикасының район үзәкләренә карамаган | 4 балл |

| | | |
|---|---|---|
| | авыл һәм шәһәр җирлекләре | |
| 5.2. | Татарстан Республикасының район үзәкләре | 3 балл |
| 5.3. | Казан һәм Яр Чаллы шәһәр округлары | 2 балл |
| 5.4. | Эшчәнлек онлайн алып барыла | 1 балл»; |

4.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант алучы тарафыннан проектны тормышка ашыруга бәйле чыгымнар һәр исем буенча шундый проектны тормышка ашыруга каралган чыгымнар күләменең кимендә 25 проценты күләмендә финанслашу шарты үтәлгән очракта, грант бирелә.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант күләме, аның максатчан билгеләнеше;

грант финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнар юнәлешләре;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, вәкаләтле органга моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки яңа шартлар буенча ризалыкка ирешкәндә килешүне өзү турында шарт;

грант алучы юридик затлар, шулай ук грант алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела;

грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;

грант алучының (социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъекты) бурычы ел саен грант бирелгән елдан соң килә торган елдан башлап өч ел дәвамында «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү

турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану шартларына туры килгәндә социаль предприятие статусын раслап торырга;

грант алучының (25 яшькә кадәрге физик зат тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъекты) бурычы ел саен грант бирелгән елдан соң килә торган елдан башлап өч ел дәвамында үз эшчәнлегенең финанс-икътисадый күрсәткечләре турында вәкаләтле органга мәгълүмат бирергә;

грантны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләүгә бәйле чыгымнарны финанслау, дәүләт микрофинанс оешмалары тарафыннан бирелгән заемнар буенча, шулай ук кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентлар түләү юнәлешендә тотуны тыю;

грант алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык тапшыру сроклары һәм формалары (кирәк булганда).»;

5.11 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Грант алучы, грант бирелгән елдан соң килә торган елның 10 июленнән дә соңга калмыйча, шулай ук квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, вәкаләтле органга Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча грант бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап һәм грант финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) (алга таба – хисаплар) тапшыра.»;

икенче абзацта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.12 пункт өстәргә:

«5.12. Грант алучы проектны гамәлгә ашыру чыгымнары юнәлешләре буенча суммаларны алынган грант күләме чикләрендә яңадан бүлү өчен вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Вәкаләтле орган грант алучының мөрәҗәгате кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә мөрәҗәгатьне карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе утырышын оештыра.

Конкурс комиссиясе бу пунктның икенче абзацында билгеләнгән срок эчендә грант алучының мөрәҗәгатен карап тикшерә һәм проектны тормышка ашыру чыгымнары юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү яки яңадан бүлүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм беркетмәне рәсмиләштерә.

Вәкаләтле орган беркетмә төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә грант алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Проектны тормышка ашыру чыгымнары юнәлешләре буенча суммаларны яңадан бүлү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган грант алучы белән конкурс комиссиясе карары кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзи.»;

VI бүлек исемендә «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Вәкаләтле орган грант алучыларның грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

6.2 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6.4 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү нәтиҗәләренә ирешүгә, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрелә.»;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

башисемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

исемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

Тәртипнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Тәртипнең 3 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Тәртипкә 4 нче кушымтада:

башисемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

Тәртипкә 5 нче кушымтада:

башисемендә татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта татар текстында «эшкуарлык субъектларына» сүзләреннән соң «яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган бу карарның 1 пунктындагы туксан сигезенче абзацыннан һәм Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 8 сентябрь, 968 нче карары редакциясендә)

Форма

Гарантия хаты

______________________________________________ (алга таба – заявка бирүче)
(юридик затның исеме, индивидуаль эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)
_______________________________________________________________ йөзендә,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))
______________________________________________________ нигезендә эш итүче
(устав, Шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры (ОГРИП) таныклыгы, ышанычнамә реквизитлары)
моның белән конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелергә планлаштырыла торган айның 15енә түбәндәгеләрне гарантияли:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле 1 мең сумнан арткан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавын;

заявка бирүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмавын;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмавын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык

субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең 1.4 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын;

заявка бирүченең Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баруын;

заявка бирүченең Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләвен;

социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен алга таба ике вариантның берсе күрсәтелә:

1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә социаль предприятие дип танылган һәм аның турында мәгълүмат агымдагы календарь елның 10 июленнән 10 декабренә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән булуын;

2) социаль предприятие дип беренче тапкыр танылуын, социаль эшмәкәрлек өлкәсендә эшчәнлек алып бару юнәлеше буенча заявка бирелгән көнгә кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булуын яки социаль предприятие статусын раславын, заявка биргән көнгә элек эшләнгән проектны гамәлгә ашыруын;

25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен:

грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик зат индивидуаль эшкуар буларак теркәлүен яисә юридик затны гамәлгә куючылар (анда катнашучылар) яки аның акционерлары составына грант алу өчен документлар тапшыру вакытына 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп), җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында яисә хуҗалык ширкәтенең җыелма капиталында кимендә 50 процент өлеше яисә акционерлык җәмгыятенең кимендә 50 процент тавыш бирү акцияләре булган физик зат керүен;

кече һәм урта эшкуарлык субъекты эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру юнәлеше буенча грант алган вакытка кадәр ел дәвамында белем бирү программасы яки акселерация программасы кысаларында укуда булуын.

____________________ ____________________________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)
20___ ел, «___» __________

Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 8 сентябрь, 968 нче карары редакциясендә)

Форма

Проект

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Социаль предприятие дип беренче тапкыр танылган кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. | Социаль предприятие статусы расланган кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.3. | 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъекты | |

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Заявка бирүче (тулы исеме):<br>Индивидуаль эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме – булганда) / Юридик затның исеме | |
| 2. | Статусы:<br>Индивидуаль эшкуар / юридик затның оештыру-хокук формасы | |
| 3. | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 4. | Теркәлү датасы: | |
| 5. | Заявка бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайты (сылтама): | |
| 6. | Заявка бирүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге социаль челтәрләре (сылтама): | |
| 7. | Проект җитәкчесе:<br>Ф.И.Ат.ис. (атасының исеме – булганда), вазыйфасы (әгәр заявка бирүченең штат хезмәткәре булса) | |
| 8. | Проектның исеме | |
| 9. | Проектның максатчан аудиториясе: | |
| 10. | Проектның әһәмиятен нигезләү: | |
| 11. | Проектның максаты: | |
| 12. | Проектны тормышка ашыру географиясе: | |
| 13. | Проектны тормышка ашыру срогы (грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 июленә кадәрге дата күрсәтелә):<br>Проект буенча төп чаралар графигын тәкъдим итәргә | |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | Проектны тормышка ашыруга каралган чыгымнар (проектның гомуми бюджеты, сумда):<br>грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 июленә кадәрге срокка | |
| | шул исәптән: | |
| 14.1. | Проектны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслашу күләме (проектны тормышка ашыруга каралган чыгымнар күләменең кимендә 25 проценты, сумда) | |
| 14.2. | Грант акчасы (сумда) | |

Грант бирү нәтиҗәсе

| | | |
|---|---|---|
| 1.1. | Һөнәри керемгә салым түләүчеләр булмаган грант алучылар өчен – штат расписаниесе (яисә башка гамәлдәге документ) нигезендә штат санын кимендә бер берәмлеккә арттыру | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. | Һөнәри керемгә салым түләүче грант алучылар өчен – һөнәри керемнәргә салым салына торган, килешү төзелгән көннән алынган керемнәрнең гомуми суммасы кимендә 10 000 сум күләмендә | |

Проект чыгымнары (грант бирү нәтиҗәләре):

| Т/с | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 12 октябрь, 971 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенең 1.4 пункты нигезендә чыгымнар [1] исеме | Тасвирламасы (чыгымнарны детальләштерү, расшифровкалау, грант акчасын тотуны раслый торган документлар исемлеге) | Саны | Грант акчасы, сум | Үз акчасы, сум | Проект-ның гомуми бюд-жеты, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| … | | | | | | |

[1]Проект буенча планлаштырыла торган чыгымнар тиешле исәп-хисаплар һәм документлар (шартнамәләр, коммерция тәкъдимнәре, интернет кибетләр мәгълүматлары һ.б.) белән расланырга тиеш.

Проектка өстәмә рәвештә заявка бирүче тарафыннан эшчәнлек үсеше планы төзелгән елдан соң килә торган өч елга әлеге план (ирекле рәвештә) теркәлә.

20__ ел, «__» ________

Заявка бирүче _____________ / _______________________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

___________________________________